СОВЕТ ШУБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
«27» сентябрь 2024 ел.

**КАРАР**
№ 110

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Шубан авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы " Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Бюджет законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Советының 11.11.2019 № 115 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 6 пунктында:

- 10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнешкә ия бүтән бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;»;

- 11 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

- 13 пунктчада «муниципаль район» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«13.1) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында, капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр формалаштыра;»;

1.2. 4 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнешкә ия бүтән бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан, аларны биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә.»;

1.3. 4 статьяның 9 пунктында:

- 6 пунктчада «бирә» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

- 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) бюджетка түләүләр буенча бурыч түләүгә ышанычсыз дип тану турында карар кабул итә;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктлар өстәргә:

«8) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджет, пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;
9) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (baltasi.tatarstan.ru) составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шубан авыл җирлеге башлыгы: С.З.Васильева.